**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

---

**2025 елның «08» декабре** **30-РС номер**

# КАРАР

## 2026 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лаеш муниципаль районы Советының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган Лаеш муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары итте:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) расларга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб—адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районының 2026 елның «___» __номерлы
карарына кушымта

# 2026 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

## I. Гомуми нигезләмәләр

2026 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Лаеш муниципаль районының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы нигезләмә нигезендә эшләнде.

Муниципаль мөлкәтне (алга таба - муниципаль мөлкәтне) хосусыйлаштыру бурычлары булып тора:

- муниципаль мөлкәт структурасын оптимальләштерү;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджетының керем өлешен тулыландыру;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә эшкуарлыкны үстерү өчен уңайлы мохит тудыру.

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә төп юнәлешләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең муниципаль мөлкәттән бертигез файдалану һәм ачыклыгы принципларына нигезләнгән үтә күренмәле һәм нәтиҗәле приватизация процедураларын куллану;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә файдаланылмаган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру.

## I. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2026 елга хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт исемлеге әлеге Программага 1 нче кушымтада китерелгән.

2026 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына(программасына) 1к кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан 2026 елга хосусыйлаштыру планлаштырыла торган биналар, корылмалар, бәкеләр һәм җир кишәрлекләре исемлеге**

| № п/п | Муниципаль мөлкәт исеме | Урнашу урыны | Бинаның, төзелешнең, корылманың мәйданы (кв. м) | Җир кишәрлеге мәйданы (кв. м) | Хосусыйлаштыруның планлаштырыла торган вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Бина (кадастр номеры 16:24:080101:1242) һәм кадастр номеры 16:24:080101:123 булган җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь ис.совхоз поселогы., Мәктәп ур., 4 й. | 180,6 | 720 | 2026 ел дәвамында |
| 2 | Административ бина (кадастр номеры 16:24:050601:10106) һәм кадастр номеры 16:24:110103:168 булган җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Хәерби ав., Мәктәп ур., 1а й. | 638,2 | 2282 | 2026 ел дәвамында |
| 3 | Административ бина (кадастр номеры 16:24:050601:1576) һәм кадастр номеры 16:24:240304:14 булган җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Сокуры ав., Мишә ур., 1 й. | 570,9 | 1313 | 2026 ел дәвамында |
| 4 | Кибет (кадастр номеры 16:24:050601:9329) һәм кадастр номеры 16:24:020101:48 булган җир кишәрлеге | ТР, Лаеш районы, Имәнкискә авылы | 206,8 | 263 | 2026 ел дәвамында |
| 5 | "Заслон" киртә секторы | ТР, Казан шәһәре, "Казан ипподромы" ҖЧҖ | 162 шт. | | 2026 ел дәвамында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Сантехник контейнерлар | ТР, Лаеш районы, Никольский авылы | 7 шт. | | 2026 ел дәвамында |
| 7 | Балалар бакчасы бинасы (кадастр номеры 16:24:160101:810) һәм кадастр номеры 16:24:160101:175 булган җир кишәрлеге | ТР, Лаеш районы, Олы Кабан ав., Овражная ур., 15 й. | 421,7 | | 2026 ел дәвамында |
| 8 | Бакча йорт (кадастр номеры 16:24:257001:518) һәм кадастр номеры 16:24:257001:26 булган җир кишәрлеге | ТР, Лаеш муниципаль районы, Орел авыл җирлеге, «Механик»коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте, 26 й. | 67,8 | 615,0 | 2026 ел дәвамында |
| 9 | "Орлов полигоны" торак булмаган бина (кадастр номеры 16:24:140601:44) һәм кадастр номеры 16:24:140601:1076 булган җир кишәрлеге | ТР, Лаеш муниципаль районы, Орел авыл җирлеге, Орел авылы | 82,0 | 100000,0 | 2026 ел дәвамында |